РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
ул. Советская, д. 41в , село Татарский Шуган, Азнакаевского муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы Азнакай муниципаль районы, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» ноябрь 2021 ел №4

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Татар Шуганы авылы Совет ур.,43,45,47,49,51 нче йорттан 90 нчы йортка, Жэлил ур., 1 нче йорттан 10 нчы йортка, Х.Такташ ур., 1 нче йорттан 22 нче йортка, Сэйдэш ур., 1 нче йорттан 25 нче йортка, Соембикэ ур., 1 нче йорттан 3 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2021 елның 26 ноябрендэ 11.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Татар Шуганы авылы Совет ур., 1 нче йорттан 42,44,46,48,50 нче йортка, Тукай ур., 1 нче йорттан 45 нче йортка кадэр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2021 елның 26 ноябрендэ 13.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Татар Шуганы авылы Яна ур., 1 нче йорттан 9 нче йортка, Ленин ур., 1 нче йорттан 31 нче йортка, Яшьлэр ур., 1 нче йорттан 12 нче йортка кадәр

теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2021 елның 26 ноябрендә 15.00 сәгатькә билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- җәйге чорда Татар Шуганы авылында территорияне чабу;
- Татар Шуганы авылын су белән тәэмин итү өчен тирәннән су алу насосын сатып алу;;
- Татар Шуганы авылында «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;;
-МТЗ-82.1 тракторы өчен кар эттергеч сатып алу;;
- трактор йөртүче хезмәте өчен түләү;
- Татар Шуганы авылында торак пункт исеме язылган стела ясау һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык М.Ш.Хәертдинов